

Авылнын жырында шулай жырлана “Арысландай Иса егетләре...” Чынлап та алар шундыйлар, ышаныгыз. Дәлилгә, vткән айны авыл хужалыгы олкәсе хезмәткәрләрен котлап vттек; нәкъ шундыйларны котладылар. Сvзебез ипи vстервчеләр турында. Анлатма кертәм: Кадошкино районы Большая Поляна авылын яратып Иса авылы дип йортәләр.

Мордовиянен авыл хужалыгы һәм эшкәртv сәнәгате хезмәткәрләре мактаулы эпитетларга лаек һәм нәкъ менә шундыйлар шактый. Алар данга яки артык игътибарга омтылмыйлар, vз эшләренен сыйфатына игътибарны юнәлтергә телиләр: тыйнаклыклары сvздә генә тvгел, эштә дә кvренә.       Мәсәлән, Кадошкино районы “Магма ХД” бvлекчәсендә Большая Поляна авылында яшәvчеләрнен әлеге коллективта унбишләп  хезмәт итvче кеше исәпләнә. Алар арасында - механизаторлар, машина йортvчеләр, слесарьлар һәм эретеп ябыштыручылар, тракторчылар, ком-байнчылар. Бу кешеләр vз эшләренә чынчынлап бирелгәннәр, ана ботен жаннарын, тырышлыкларын, шәхси вакытларын кызганмый хезмәт итәләр. Әлеге авылда хезмәткә мәхәббәт, әйтерсен, генетик дәрәжәдә салынган- буыннан-буынга кvчә. Абыйлы-энеле Руслан белән Марат Ханиковлар механизаторлар - тракторчылар, комбайнчылар. Эшкә һәвәслекне vз эшләренен чын осталары булган әтиләреннән, Фәрит Айса улыннан мирас итеп алганнар һәм һәрвакыт балаларына топ vрнәк булып тора. Әтисе, Фәрит Айса улы, озак еллар авылларындагы “Победа” колхозында алыштыргысыз механизатор булып эшләгән, ә хәзер лаеклы ялда. Руслан Фәрит улы да бу юлны сайлаган. Дvрт елга якын слесарьлык һонәрен тулысынча vзләштерә. Ире-шелгәннәрдә генә тукталып кал-мыйча, югары класслы механизатор да. Анын осталыгы комбайн һәм трактор белән идарә итvгә генә тvгел, аларны ремонтлауга да кагыла. Теләсә кайсы маркалы авыл хужалыгы

машинасын тәртипкә китерергә сәләтле. Жәйге чорда ул тулысынча кыр эшләрендә - комбайн штурвалы артында. Кыш коне аны трактор руле артында кvрергә була: ул JohnDeere комбайнын ремонтлап бетерә дә, кыш коне JohnDeere тракторын фермаларда салам ваклау һәм башка кирәкле эшләрне башкару очен кулланырга планлаштыра. Жирдә, авыл хужалыгында эшләv ана чын канәгатьлек китерә. Анын двоюродный браты да, Марат Иниятулла улы Хаников, яшьтән vк авыл хужалыгы доньясына чума. Анын бу олкә белән танышуы бишенче сыйныфта ук, жәйге каникулларын комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгәндә vк башлана. Жиргә һәм техникага булган бу дәрт ана тирә-юньдә танылган механизатор булган әтисе Иниятулла Айса улы Ханиковтан кvчкәндер. Иниятулла Хаников безнен янда булмаса да, анын изге эшләре һәм якты истәлеге авылдашларынын кvнелендә мәнгегә сакланып калган. Армиядә хезмәт иткәннән сон, Марат Иниятулла улы Кадошкино районы кулланучылар жәмгыятендә (РАЙПО) машина йортvче булып эшли башлый. Аннары туган авылы колхозында механизатор һәм комбайнчы була. Алтын куллары һәм табигый осталыгы ана теләсә нинди бурычны жинел башкарып чыгарга момкинлек бирә. Ә Кадошкино бvлекчәсе барлыкка килгәч, Марат Хаников vзе очен яна һонәр- тракторчы һонәрен vзләштерә һәм берникадәр вакыттан сон ул ышанычлы һәм оста итеп тракторларнын торле модельләрен йортә башлый. Менә инде дvрт сезон рәттән JohnDeere заманча техникасында комбайнчы булып эшли. Урып-жыю тәмамлангач, браты шикелле тракторда эшли: кар кери һәм башка кирәкле эшләрне башкара. Кыскасы, эшсез утырырга туры килми ана. Мәгълvм булганча, авыл хужалыгы техникасы даими кайгыртуны һәм ремонтлауны таләп итә; бу эштә дә Марат Иниятулла улы һәрторле жимерекләрне жинел генә табып тезәтә. Коллективы да аны яхшы дус һәм югары профессионал дип тасвирлый.
Большая Поляна авылында яшәvче Дамир Шамиль улы Альмяшев топ һонәре буенча эретеп ябыштыручы (сварщик). Бу белгечлекне Рузаевка училищесында алгач, тормыш аны авыл хужалыгына алып килә. Аграр олкәгә юл туры булмый. Башта Дамир Шамиль улы Кадошкино электротехника заводында йок тоягеч погрузчикта эшләгән, әмма бервакыт эшчәнлек торен кардиналь рәвештә vзгәртергә карар кылган һәм “Магма ХД” компаниясенә килгән. Тракторчы булып эшли башлаган булса да авыл хужалыгында универсальлекнен беренче урында икәнен бик тиз анлаган. Бvген ул тракторчы гына тvгел, механизатор да, комбайнчы да. Дvрт ел эшләv дәверендә катлаулы техниканы vзләштерә. Куәтле JohnDeere комбайны аны ярты сvздән тынлый: машина белән кvптән “син”гә һәм мондый жайга салынган эш нәтижәләре һәрвакыт соендерә. Урып-жыюнын кызу вакытында Дамир Шамиль улы, якташ дуслары кебек vк, кырда кичкә кадәр эшли, ә салкыннар башлангач тракторга утыра. Ә бит башта “Беларус” тракторына иялэшергә туры килсә, бvген чит илнеке JohnDeere да, комбайнны да буйсындырган. Жиргә һәм техникага мәхәббәт Дамирнын канында дип әйтергә була. Әтисе, Шамиль Шакир улы, ботен гомерен туган авылына багышлаган, “Победа” колхозында мәктәп эскәмиясеннән vк тракторчы булып эшләгән. Улы гаилә династиясен лаеклы дәвам итә; vз эшенә тугрылык һәм хезмәт соючәнлек- топ нәрсә икәнен исбатлый.
Уныш амбарларда, игенчеләребез кышка әзерләнә. Кон саен жәмгыять файдасына хезмәт куючыларга, кыенлыкларны жинеп, аграр секторнын тотрыклы vсеше очен шартлар тудыручыларга рәхмәтлебез. Менә шундый тырыш, унган, арысландай Иса егетләре.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**, *фото - “Возрождение” газетасы сайтыннан*